Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Кульга авыл җирлеге Советы

**КАРАР № V-9**

Олы Кульга авылы 2019 елның 13 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлеге Советының 2014 елның 8 октябрендәге VII-10 номерлы “Җир салымы турында” карарына үзгәрешләр кертү турында»

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында 15.04.2019 ел, №63-ФЗ «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм «Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 9 статьясына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Олы Кульга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» гы 2014 елның 8 октябрендәге VII номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 июнендәге VIII-13 номерлы, 2017 елның 11 сентябрендәге VII-12 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәхси хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3% тәшкил итә»;

1.2) Знче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«I һәм II группа инвалидлыкка ия булган инвалидлар, балачактан инвалидлар, инвалид балалары булган гаиләләр, күп балалы гаиләләр, торак фонды, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, яшелчәчелек яки терлекчелек өчен бирелгән җир кишәрлекләренә, шулай ук дача хуҗалыгына, милектәге авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә, даими (сроксыз) яки гомерлек мирас итеп

файдалану өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата».

2. Әлеге карар, әлеге карарның 3 пункты үз көченә керүнең башка вакыты билгеләнгән Нигезләмәдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлеге Советының «җир салымы турында» гы 2014 елның 8 октябрендәге VII карарының 2 пунктындагы 4 абзацына кертелгән үзгәрешләр 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Кульга авылы, Мәктәп урамы, 11 йорт; Кече Кульга авылы, Первомайская урамы, 1 йорт; Дон-Урай авылы, Бакча тыкрыгы, 2 йорт; Олы Осиновка авылы, Кооперативная урамы, 1 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Олы Кульга авыл җирлеге башлыгы Е.А.Терентьев